| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА<br>И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ<br>ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | г.Казань | **БОЕРЫК** |
| **19.06.2023** | **Казан шәһәре** | **№ 218/2-пр** |

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы нигезендә б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге боерыкның үтәлешен үзем тикшереп торам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр М.А. Җәббаров

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгының
2023 елның ___ ____________
___ номерлы
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Министрлыкта коррупция һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре (алга таба – дәүләт хезмәткәре), Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы булмаган вазыйфаны биләүче хезмәткәр (алга таба – хезмәткәр), шулай ук Министрлыкка караган учреждение җитәкчесе (алга таба – учреждение җитәкчесе) тарафыннан даими рәвештә акча таләп итү, гражданнарның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре кысылу, хезмәт тәртибе таләпләре бозылу, шулай ук хезмәт урыныннан усал ниятләр белән файдалану билгеләре булган башка гамәлләрне үз эченә алган фактлар турында белешмәләрне үз эченә алган коррупция юнәлешендәге фактлар буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба - Министрлык) кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау үзенчәлекләрен билгели.

2. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлә һәм карала.

3. Мөрәҗәгать, Министрлыкта теркәлгәннән соң, Министрлыкның кадрлар бүлегенең Министрлыкта коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затына (алга таба – коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат) карау өчен җибәрелә.

4. Кергән мөрәҗәгатьтә әзерләнә, башкарыла торган яисә башкарылган законсыз гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яисә башкарган зат турында белешмәләр булганда, андый мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә компетенцияләренә туры килә торган хокук саклау органнарына җибәрелә.

5. Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып биш көн эчендә аны карый, андагы белешмәләргә башлангыч анализ ясый, әлеге белешмәләрне анализлаганда дәүләт хезмәткәре, хезмәткәр, учреждение җитәкчесе белән әңгәмә үткәрә һәм алардан үзләренең ризалыгы белән кирәкле аңлатмалар ала.

6. Мөрәҗәгатьтә дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (эш итмәүләрендә) коррупциячел хокук бозулар булуны күрсәтә торган белешмәләр ачыкланган очракта, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен

җаваплы зат аңа карата тикшерү уздыра башлый (Тәртипнең әлеге пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш).

Дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәвен тикшерү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда уздырыла. Тикшерү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрына (аның вазыйфаларын башкаручы затка) (алга таба - министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тикшерү тәмамланган датадан исәпләнә торган ике эш көне эчендә язма доклад рәвешендә хәбәр ителә.

Мөрәҗәгатьтә дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (эш итмәүләрендә) коррупциячел чагылышлар булу турында бәян ителгән фактлар тикшерү нәтиҗәләре буенча министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан расланган очракта, доклад ул алынган көннән ике көн эчендә Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүләре һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясенә карау өчен җибәрелә. Әлеге комиссиянең күрсәтмәсен исәпкә алып, министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан дәүләт хезмәте турындагы законнар нигезендә дәүләт хезмәткәренә карата җаваплылык чарасын куллану мәсьәләсе хәл ителә.

Дәүләт хезмәткәренең ризалыгы белән һәм ул коррупциячел хокук бозу фактын таныганда, җәза, ышанычны югалту аркасында эштән азат итүдән тыш, Министрлыкның кадрлар бүлегенең коррупциячел хокук бозу турындагы доклады, анда факттагы хәлләр бәян ителгән була, һәм дәүләт хезмәткәренең язмача аңлатмасы нигезендә билгеләнергә мөмкин (Тәртипнең әлеге пунктында каралган тикшерүне уздырмыйча гына).

7. Мөрәҗәгатьтә хезмәткәрнең, учреждение җитәкчесенең гамәлләрендә (эш итмәүләрендә) коррупциячел хокук бозулар булуны күрсәтә торган белешмәләр билгеләнгән очракта, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат хезмәткәрнең, учреждение җитәкчесенең гамәлләрендә (эш итмәүләрендә) коррупциячел хокук бозуларның булу-булмавын ачыклау өчен мөрәҗәгатьтә бәян ителгән хәлләргә тикшерү уздыра башлый.

Тикшерү министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) карары буенча уздырыла һәм мөрәҗәгать теркәлгән датадан исәпләнә торган 10 эш көне эчендә тәмамланырга тиеш. Тикшерүне уздыру, кирәк булса, Министрлыкның башка бүлекчәләрен дә җәлеп итеп, Министрлыкның кадрлар бүлегенә һәм юридик бүлегенә йөкләнә. Тикшерү нәтиҗәләре турында министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) тикшерү тәмамланган датадан исәпләнә торган ике эш көне эчендә язма бәяләмә рәвешендә хәбәр ителә. Тикшерү уздыруның тәмамлануы аны уздыру нәтиҗәләре буенча бәяләмә имзаланган датадан санала.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча хезмәткәрнең, учреждение җитәкчесенең гамәлләрендә (эш итмәүләрендә) коррупциячел чагылышлар булу турындагы мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар расланган очракта, хезмәткәрнең, учреждение җитәкчесенең язма аңлатмаларыннан чыгып, министр (аның вазыйфаларын башкаруы зат) тарафыннан хезмәт турындагы законнар нигезендә аңа карата җаваплылык чарасын куллану мәсьәләсе хәл ителә.

8. Әзерләнә, башкарыла торган яисә башкарылган законсыз гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яисә башкарган зат турында хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча билгеле булган очракта, тиешле мәгълүмат комиссия бәяләмәсе алынган көннән өч эш көне эчендә компетенцияләренә туры килә торган хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

9. Мөрәҗәгать җибәргән гражданга җавап әзерләүне коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат башкара.

10. Мөрәҗәгатьтә коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затның гамәлләрендә (эш итмәүләрендә) коррупциячел чагылыш фактлары турында белешмәләр булган очракта, андый зат, үз-үзен кире кагып, мөрәҗәгатьне карауда катнашмый. Мондый мөрәҗәгатьне карауны һәм мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга җавап әзерләүне әлеге Тәртип нигезендә Министрлыкның кадрлар бүлеге башкара.